**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Приоритет-2030» стратегияле академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында аэрокосмик, транспорт, фотон һәм квант системалары өлкәсендә эшләнмәләрнең яңа суверен технологик линияләрен булдырып тикшеренүләр уздыру һәм мәгариф программаларын гамәлгә ашыру максатларында 2025 елга югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү грантын гамәлгә кую турында**

«Приоритет-2030» стратегияле академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында аэрокосмик, транспорт, фотон һәм квант системалары өлкәсендә эшләнмәләрнең яңа суверен технологик линияләрен булдырып тикшеренүләр уздыру һәм мәгариф программаларын гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. «Приоритет-2030» стратегияле академик лидерлык программасын гамәлгә ашыру кысаларында аэрокосмик, транспорт, фотон һәм квант системалары өлкәсендә эшләнмәләрнең яңа суверен технологик линияләрен булдырып тикшеренүләр уздыру һәм мәгариф программаларын гамәлгә ашыру максатларында 2025 елга югары белем бирү мәгариф оешмасын үстерү программасына ярдәм күрсәтү грантын гамәлгә куярга.

2. «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесен грант алучы дип билгеләргә.

3. Грант түләүгә Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләренең күләме 100,0 млн сум тәшкил итә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
грант бирү тәртибен расларга;
әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;
грантны максатчан куллануны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;
әлеге Указның үтәлүен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 17 октябрь
№ 869